# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

28 ноябрь, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1 2025 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Югары-Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2 Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) *торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;* (Югары-Чура авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылы юлларына вак таш җәю һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, чапкыч һәм запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәтләре,

(Югары-Чура авылында кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территориянең печәнен чабу, төзекләндерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(тукталыш павильоннары сатып алу, ясау һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(тукталыш павильоннары сатып алу, ясау һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(юл билгеләрен һәм тамгаларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

2) *тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау*(Югары-Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3) *су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау* (Югары-Чура авылына насослар сатып алу, урнаштыру, артезиан скважиналарын, су саклау зоналарын карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары-Чура авылына су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, Югары-Чура авылы су суырту манарасы территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

4) *янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү* (янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне колонкаларны, мотопомпаны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

5) *традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма кору, ремонтлау* (Югары-Чура авылында зиратны карап тоту, зиратны киртәләү өчен материал сатып алу,проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(будка сатып алу, ясау һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

6) *торак пункт территориясен төзекләндерү* (Югары-Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Югары-Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төплә һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру).

3. Әлеге карарны Югары Чура авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы: Р.Т.Мифтахов